| Республика Татарстан<br>**СОВЕТ**<br>**ЛЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО**<br>**ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО**<br>**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | Татарстан Республикасы<br>**САРМАН**<br>**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**<br>**ЛӘКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**<br>**СОВЕТЫ** |
| --- | --- |

**Решение** **Карар**

2025 ел, 16 нчы декабрь № 10

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районының
Ләке авыл җирлегендә
муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү хакында

"Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында" 03.10.2025 елгы 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Сарман муниципаль районының «Ләке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Ләке авыл җирлеге Советы:

1. Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Советының 2022 елның 14 февралендәге 3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (Советның 25.11.2022 елгы 21, 22.02.2023 елгы 4, 08.04.2023 елгы 13, 09.08.2023 елгы 16, 08.11.2023 елгы 19, 28.12.2023 елгы 27, 26.03.2024 елгы 1, 21.06.2024 елгы 6, 07.11.2024 елгы 14, 23.11.2024 елгы 17 номерлы карарлары редакциясендә), түбәндәге үзгәрешләр кертергә:
2.5 пунктның 2,3 абзацлары. түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен түбәндәге типик квалификация таләпләре билгеләнә:
1) һөнәри белем дәрәҗәсенә карата: югары белем булу - вазыйфаларның Югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен, авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларның Югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен; югары белем яисә урта һөнәри белем булу - авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларның Югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен, шулай ук вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен;
2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына: муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча-кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы; муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча-муниципаль хезмәт яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә бер ел эш стажы.".

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» халыкка җиткерергә (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы»муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге
Совет Рәисе Ю. Г. Антонов